| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РОДНИКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ РОДНИК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Родники **КАРАР**

12.05.2023 № 7

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 мартындагы 6 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану кагыйдәләрен раслау турында»карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 июнендәге 193-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә

карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- су объектларының башка милекчеләренең, су кулланучыларның хокукларын бозуга, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә) зыян китерүгә юл куймаска (алга таба-мәдәни мирас объектлары);»;

1.2. 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Гидротехник корылмаларны проектлау, төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләгәндә мәдәни мирас объектларын саклау буенча чаралар, су объектларын, шулай ук су биологик ресурсларын һәм хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының башка объектларын саклау буенча чаралар каралырга һәм вакытында гамәлгә ашырылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Родники авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе** **Е.А.Яковлева**